# Чишмә башы

Безнең белән бер дулкында бул!

Декабрь, 2025

***Яңа ел белән , дуслар!***

**Эшләрегез һәрвакыт уң булсын, гөрләп алга барсын, күңелегездә булган мәрхәмәтлелек нуры җаннарыгызны тагын да ягымлы, матур итсен, ялкынландырып бизәп торсын. Йортларыгызга караңгылык, салкынлык, хәвеф-хәтәр кермәсен, бәла-каза килмәсен. Гаилә бәхетегез сүнмәсен, гел балкып торсын!**

***Яңа ел белән !***

***Яңа ел бит ул могҗиза, Яңа ел — тылсым. Яңа елда һәр кылган эш бәхеткә булсын! Карлар белән бергә җанга ак өмет иңсен. Яңа елда бар җиһанны тынычлык төрсен!***

***Яңа елда, яңа шатлык,<br>Яңа бәхет кенә булсын<br>Имин булсын илләр-<br>көннәр Кайгы-хәсрәт урап<br>узсын.***

## Ә Сез беләсезме?

*якынлаша!*

**1700 елда Петр I әмере буенча 1 гыйнвар көнне билгели башлыйлар. Әлеге карар буенча Яңа ел бәйрәменә өйләрне Гостиный дворда куелган үрнәк буенча нарат, чыршы ботаклары белән бизәргә кирәк була. Бәйрәм рухы тудыру өчен кешеләрнең бер-берсен котлавы мәҗбүри куела.**

**Ул чорда Мәскәүдәге Кызыл мәйданда утлы өермә уйнатыла, туплардан һәм мылтыклардан салют бирелә. Мәскәүлеләр өйләре янында мушкеттан атарга һәм ракеталар очырырга тиеш булалар.**

**1917 елгы инкыйлабтан соң Яңа елны һәм Раштуаны бәйрәм итү туктатыла.**

**1935 елда исә, балалар бәйрәме буларак, кире кайтарыла.**

**1937 елның гыйнвар башында Мәскәүнең Колонналы залында беренче тапкыр рәсми Чыршы утлары кабызыла. Аннан соңгы елларда ил буйлап меңнәрчә чыршылар бизәлә. 1947нче елның 23 декабрендә СССР Югары Советы президиумы указы белән 1 гыйнвар бәйрәм һәм ял көне дип игълан ителә. Ә ел башындагы рәсми ял көннәре 2005 елдан кертелә.**

## 2026 ел Россиядә һәм Татарстанда.

**2026 ел Россиядә милләтләр һәм халыклар арасындагы бердәмлекне ныгыту максатыннан “Россия халыкларының бердәмлеге елы” дип игълан ителде. Республикабыз исә бу елны төрле чорларда Ватанны саклап көрәшкән һәм тылда тырыш хезмәт куйган һәркемгә олы ихтирам йөзеннән “Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы” дип игълан итте.**

# *Кышның энҗе-мәрҗәннәре*

## *Балалар иҗаты*

### Туган ягыма кыш килде.

Туган ягыма кыш килде. Бар дөньяны ап-ак кар каплады. Салкын һава битләрне өшетә. Энҗе кар бөртекләре йомшак кына керфек очларына куна да, минем сулышымнан эреп юкка чыга. Ә менә агачлар энҗе бөртекләрдән мамык шәл бәйләп бөркәнгәннәр. Шәлләренә нәфис бизәк булып кызылтүшләр тезелгән.

Бу сихри җиһанга кояш үзенә бертөрле серлелек өсти. Җир өслегендә ялтырап яткан энҗе-мәрҗәннәр күз явын алырлык! Кыш бик матур ел фасылы шул!

Шакирова Ралинә, 5 сыйныф

### Кышкы урман

Ап-ак булып кышкы урман
Серле тынлыкка чумган.
Әйтерсең,бар тереклек
Татлы йокыга талган.

### Күңелле кыш

Әй күңелле кыш көне,
Чөнки яңа ел килә.
Кыш бабабыз күп итеп
Күчтиләр алып килә.

Гатауллина Диләрә, 4 сыйныф

### Кыш

Авылга ак кыш килгән,
Агачлар ак тун кигән.
Урманнарга-кырларга
Көмеш тәңкә сибелгән.
Төнен тәрәзәгә ул
Ясап киткән бизәк тә.
Салкын булса да кышын,
Рәхәт инде бигрәк тә.

Абдрахманова Камилә,
5 сыйныф

### Кышның мамык шәле бар...

Бөтен дөньяны ап-ак кар каплады. Табигать җем-җем итеп торган яңа матур күлмәген киде. Агачлар да җылы мамык шәлләрен ябынды. Елгалар, күлләр көзге кебек шома боз белән капланды. Урман кырлар өстендә тантаналы тынлык.

Кыш көне көннәр салкын булса да, без курыкмыйбыз. Барыбыз җыелышып тауга барабыз. Чана, чаңгы, тимераякта шуабыз. Безнең тавыштан тау яны шау-гөр килеп тора. Мин кышны яратам. Кыш - елның иң матур ел фасылы.

Вәлиева Сөмбел, 5 сыйныф

### Шыгыр-шыгыр кар таптап...

Кыш килде. Ул бөтен дөньяга ап-ак юрганын каплады. Җәнлекләр кар юрганы астында тирән йокыга талды. Агачларга бәс кунды.

Тышта салкын. Ә без шыгыр-шыгыр кар таптап, урамда йөрибез. Төрле кышкы уеннар уйныйбыз. Мин туган ягымны да, туган ягымның кышын да яратам.

Хидиятуллина Зифа, 4 сыйныф



### Буранлы кыш

Буранлы кыш килә дә
Бар дөньяны ак итә.
Агачларны,түбәләрне,
Юлларны күмеп китә.

Һәркем йокыдан уянып,
Тәрәзәгә күз сала.
Яше-карты бергәләп,
Үзенә сукмак сала.

Эшчеләр эшкә барырга
Машинасын кабыза.
Юлга чыкса,кар өеме
Тора алар каршында.

Бакиев Расих, 5 сыйныф